МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.05.2021 г.Казань № 331

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 24 маенда 7681 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 24 маендагы 331 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №395, 28.11.2016 №668, 08.06.2017 №349, 15.05.2018 №367, 24.09.2018 №897, 21.02.2019 №129, 19.04.2019 №285, 10.09.2019 №688, 14.11.2019 №1007, 05.02.2020 №65, 08.05.2020 №289, 14.07.2020 №515, 28.10.2020 №764, 30.03.2021 №171 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) боерыгы белән расланган «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламнт):

1 бүлектә:

1.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.2. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Үзәк бүлекчәсе урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алыныргa мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматлардан торган, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында (алга таба – Министрлык), Үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр

белән эшләү бүлекчәләрендә урнашкан хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):-

Министрлыкның - http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла;

3) Үзәк бүлекчәсенә, Үзәккә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлекчәсенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә дә)(электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru).»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

ИАБС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәт-

кызлар) җитмәгән гражданнар өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлекчәсеннән үзләренең 2018 елның 31 декабренә әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүләре турында белешмә тапшыралар.

5. Бала тууны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмалардан – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә дә алына.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза кәгазенең электрон формасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

Үзәк бүлекчәсенә яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасында документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны.»;

2.7 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы.

2. Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча булмаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Таләпләр»;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-расламаны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан броньлап кую өчен кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «, Таләпләр» сүзен өстәргә;

3 бүлекнең 3.3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризаны Үзәк бүлекчәсенә әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны теркәп тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуның сәбәпләрен язмача аңлатып, документларны почта, электрон почта аша кайтара. Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә - гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза һәм документлар Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша килгәндә яки почта, «Интернет» челтәре аша электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә. Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша, электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә.-

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән язу, документларны кабул итүдән баш тарту турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә баш тарту турында хәбәр итү, мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 №821, 07.06.2016 №317, 20.07.2016 №420, 28.11.2016 №668, 27.02.2017 №104, 08.06.2017 №349, 28.05.2018 №401, 18.09.2018 №857, 04.02.2019 №77, 07.05.2019 №322, 10.09.2019 №689, 14.11.2019 №1021, 24.03.2020 №192, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №691, 24.02.2021 №102 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.2. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Үзәк бүлекчәсе урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Үзәк бүлекчәсендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

тәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)).»;

2.3 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;

смс-хәбәр телефонына.»;

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Социаль түләүләр алу өчен федераль законнар нигезендә банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган счет реквизитларын күрсәтеп, субсидия-ташламалар бирү турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2. Күпфатирлы йортларда торак урыннарның милекчеләре өстәмә рәвештә аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.

3. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә эш урыныннан субсидия-ташлама алу хокукы турында белешмә дә тапшыра.

4. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 41 пунктчасында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән никахны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе.

5. 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарында каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-

63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләр, гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өстәмә рәвештә гаризаны Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр (алга таба – Таләпләр)» сүзләрен өстәргә;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

даими яшәү урыны буенча законнар нигезендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданин белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында;

инвалидлык билгеләү факты турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

тууны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны.»;

2.7 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Таләпләр»;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Таләпләр»

2.16 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «, Таләпләр» сүзен өстәргә;

3.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче субсидия-ташлама билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлекчәсенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документларны теркәп тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Үзәк бүлекчәсенә почта, электрон почта, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша җибәрелгән гариза мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә гаризаны һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелә.

Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, кергәндә беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткән очракта) турында тамгалап язу тапшыра, гаризаны теркәү турындагы белдерүне почта, электрон почта аша (документлар почта, электрон почта аша җибәрелгән очракта) җибәрә яисә гаризаны теркәү турындагы белдерүне Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрә (гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

08.06.2020 №400, 04.09.2020 №609 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.2. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Үзәк бүлекчәсе урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Үзәк бүлекчәсендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.5.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы рәсми сайтында - http://www.mtsz.tatarstan.ru. Рәсми сайтта Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.5.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла;

3) Үзәк бүлекчәсенә, Үзәккә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлекчәсенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә дә)(электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru).»;mailto:mtsz@tatar.ru).

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр

кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзасы булып торса. Контракт буенча хәрби хезмәт уза торган, яшәү урыны буенча хәрби часть адресы буенча теркәлгән, ләкин хезмәт торак урыннары булмавы аркасында төзелгән найм (поднайм) килешүе шартларында торак урыннарда яши торган мөрәҗәгать итүче субсидия бирү турындагы гаризага шәхси торак фондында найм (поднайм) килешүе күчермәсен һәм хәрби частьтән хезмәт буенча торак урын бирү мөмкинлегенең булмавы турында белешмә терки;

мөрәҗәгать итүче белән аның белән бергә аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән, ләкин гаризада аның гаилә әгъзалары сыйфатында күрсәтелмәгән гражданнар тарафыннан торак урынны ремонтлау һәм карап тоту һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен раслый торган документлар;

мөрәҗәгать итүченең чит ил гражданинына һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе белән субсидия бирүне күздә тотучы халыкара килешү төзелгән дәүләт гражданлыгына караганлыгын таныклый торган документларның күчермәләре;

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының субсидия бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәре турында белешмәләр.

Мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре булмаган очракта, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә гражданнарның керемнәре булмавын раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра, аларга түбәндәгеләр керә:

а) 23 яшькәчә булган, урта һөнәри белем бирүнең һәм югары белем бирүнең төп мәгариф программалары буенча белем бирү оешмаларында көндезге формада укучы гражданнар өчен, - стипендия булмавы турында белешмә;

б) гражданнарның эшкә урнашу мөмкинлеге булмаган яки чикләнгән затлар категорияләренә каравын раслаучы документ, аларга түбәндәгеләр керә:

беренчел тикшерү һәм суд тикшерүе чорында сак астында тотылучы затлар;

дәвамлы стационар дәвалавында булган затлар (шундый дәвалау чорына);

билгеләнгән тәртиптә билгесез югалган яки үлгән дип игълан ителгән чорына кадәр эзләтүдә булган затлар;

3 яшенә житкәнчегә кадәр бала караучы, 1,5 яшенә житкәнче баланы карау буенча отпуск чорында ай саен түләнә торган пособие һәм хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган һәм 3 яшенә кадәр бала карау буенча отпускта торучы гражданнарга ай саен түләнә торган компенсация түләвен алмаучы аналар.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында;

балага опека билгеләнүе турында;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында;

дәүләтнең яки муниципаль торак фондындагы торак урыннан файдалануның хокукый нигезләре булуы турында;

мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында;

эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтәнчә түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашуы чорында түләнә торган түләү, шулай ук вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарга түләүләр турында;

торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүләр турында;

торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү буенча социаль ярдәм чаралары сыйфатында алына торган түләүләрнең күләме турында;

пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә айлык матди тәэминатлар һәм күләмнәре турында;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында;

Россия Федерациясе Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында;

житештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса;

вакытлыча эшкә сәләтсез булган чордагы пособиеләр турында;

йөклелек һәм бала табу буенча  социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнары тарафыннан түләнә торга нпособие күләме турында;

йөклелекнең башлангыч чорында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга  социаль яклау органнарыннан яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарыннан бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында;

бала карау буенча  социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торга нпособие күләме турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «, Таләпләр» сүзен өстәргә;

2.16 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әгәр мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән барлык документларны яки аларның бер өлешен электрон документлар рәвешендә тапшырмаган булса, субсидия бирү турындагы гаризаны карау бер айдан артмаган вакытка туктатыла.

Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән барлык документларны яки аларның бер өлешен тапшырмаган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинеты аша ун көнлек срокта җитешеп бетмәгән документларны тапшыру зарурлыгы турында хәбәр итә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү турында Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинеты аша мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинеты аша мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәүдән баш тарту турында нигезләр булуы турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрне исәпкә алып, гариза һәм документлар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркшү журналында теркәү язуы, документларны кабул итүдән баш тарту, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры - аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенен), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, - аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;